КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 27 сентябрь

г.Казань

№ 838

2024 елда җирле үзидарә органнарының локаль чистарту корылмаларының инженерлык челтәрләрен төзү вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2024 елда җирле үзидарә органнарының локаль чистарту корылмаларының инженерлык челтәрләрен төзү вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 11 июль, 542 нче
карары белән расланды

2024 елда җирле үзидарә органнарының локаль чистарту корылмаларының инженерлык челтәрләрен төзү вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2024 елда җирле үзидарә органнарының локаль чистарту корылмаларының инженерлык челтәрләрен төзү вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында, җир кишәрлекләрен, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын алу, локаль чистарту корылмаларының инженерлык челтәрләрен төзүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алганда хокук ияләренә китерелгән зыяннарны каплау өлешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү механизмын, максатларын һәм шартларын билгели (алга таба - тиешенчә башка бюджетара трансфертлар, чаралар).

2. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган башка бюджетара трансфертлар белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

3. Башка бюджетара трансфертлар Министрлыкка бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.P59

4. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары:

финанс белән тәэмин итү максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган муниципаль ихтыяҗлар өчен алынырга тиешле җир кишәрлекләре һәм аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектлары исемлеген күрсәтеп, чаралар булган муниципаль берәмлекнең хокукый акты булу;

муниципаль берәмлек бюджетында муниципаль берәмлекнең финанс белән тәэмин итү максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре кирәкле күләмдә булу;

әлеге Тәртипнең 11 пункты нигезендә финанс белән тә\мин итү максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү буенча муниципаль берәмлек йөкләмәсе күздә тотыла торган башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү һәм килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык.P106

5. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органы Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирүгә заявка (алга таба – заявка);

вәкаләтле зат тарафыннан расланган һәм муниципаль берәмлек бюджетында финанс белән тәэмин итү максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә

торган чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булуны раслый торган агымдагы финанс елына һәм план чорына муниципаль берәмлек бюджеты (җыелма бюджет исемлеге) турында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының кабул ителгән карарыннан өземтә;

финанс белән тәэмин итү максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган муниципаль ихтыяҗлар өчен алынырга тиешле җир кишәрлекләре һәм аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектлары исемлеген күрсәтеп, чаралар булган муниципаль берәмлекнең хокукый актының таныкланган күчермәсе;

башка бюджетара трансфертлар исәбеннән муниципаль ихтыяҗлар өчен алынырга тиешле җир кишәрлекләре, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектлары исемлеге;

җир кишәрлекләрен, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын алу һәм мондый алу хокукына ия булучыларга китергән зыянны каплау турындагы килешүләрнең таныкланган күчермәләре яисә законлы көченә кергән суд актларының таныкланган күчермәләре.

6. Әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документлар Министрлыкта алар кергән көнне теркәлә.

7. Министрлык әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә документларны карап тикшерә һәм башка бюджетара трансфертлар бирү турында йә башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында карар кабул итә, бу хакта муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органына карар кабул ителгән көннән биш эш көне эчендә хәбәр итә.

8. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

муниципаль берәмлек тарафыннан әлеге Тәртипнең 4 пунктында билгеләнгән шартларны үтәмәү;

әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларны муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан тапшырылган документларның, аларда булган белешмәләрнең әлеге Тәртиптә каралган таләпләргә һәм шартларга туры килмәве;

муниципаль берәмлек җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитларының булмавы.

9. Муниципаль берәмлек (О) бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$O = P_1 + P_2 + P_3,$$

монда:

$P_1$ - локаль чистарту корылмаларының инженерлык челтәрләре төзелешенә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен алуга бәйле чыгымнар күләме;

$P_2$ - локаль чистарту корылмаларының инженерлык челтәрләре төзелешенә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрендә урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын алуга бәйле чыгымнар күләме;

$P_3$ - локаль чистарту корылмаларының инженерлык челтәрләре төзелешенә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыянны каплау белән бәйле чыгымнар күләме.

10. Җир кишәрлекләрен, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын алуга һәм локаль чистарту корылмаларының инженерлык челтәрләрен төзүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыянны каплауга бәйле чыгымнар күләме бәйсез бәяләүгә таянып яки законлы көчкә кергән суд актлары нигезендә билгеләнә.

11. Башка бюджетара трансфертлар бирү Министрлык һәм муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органы арасында Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгының «Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетка башка бюджетара трансферт бирү турындагы килешүнең бертип формасын раслау хакында» 2021 елның 18 декабрендәге 17-112 номерлы боерыгы белән расланган бертип форма (алга таба - бертип форма) буенча төзелә торган килешү нигезендә башка бюджетара трансфертлар бирү турында Министрлык тарафыннан карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көннән артмаган срокта гамәлгә ашырыла.

12. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме;

башка бюджетара трансфертларны күчерү сроклары һәм тәртибе;

башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткече;

муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту;

финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнар турында хисап һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән башка бюджетара трансфертлар һәм йөкләмәләр бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыру тәртибе, формасы һәм сроклары;

әлеге Тәртиптә билгеләнгән шартлар бозылган очракта килешүне өзү тәртибе;

якларның җаваплылыгы;

башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенең билгеләнгән күрсәткеченә ирешмәү нәтиҗәләре.

13. Муниципаль берәмлек бюджетының финанс белән тәэмин итү өчен башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре күләме, башка бюджетара трансфертлардан бирү нәтиҗәсенең килешүдә билгеләнгән мәгънәсенә ирешү зарурлыгыннан чыгып, муниципаль берәмлек бюджеты турындагы карар белән раслана (җыелма бюджет исемлегендә билгеләнә).

14. Башка бюджетара трансфертлар күчерү Министрлык тарафыннан килешүдә билгеләнгән срокларда муниципаль берәмлекнең финанс органы өчен Федераль казначылык Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган бердәм счетка гамәлгә ашырыла.

15. Муниципаль районның вәкаләтле җирле үзидарә органы Министрлыкка бертип формасына теркәлә торган формалар буенча финанс белән тәэмин итү максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнар турында хисап һәм башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисапны килешүдә каралган срокларда тапшыра.

Планлаштырылган чаралар үтәлмәгән очракта, хисапларга теркәлә торган аңлатма язуында үтәлмәү сәбәпләре һәм муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан кабул ителгән чаралар турында мәгълүмат бирелергә тиеш.

16. Башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе - алынган җир кишәрлекләре, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектлары саны һәм локаль чистарту корылмаларының инженерлык челтәрләрен төзү максатларында муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыяннарны каплау.

Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү Министрлык тарафыннан башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәсенең Килешүдә билгеләнгән һәм фактта ирешелгән мәгънәләрен чагыштыру нигезендә гамәлгә ашырыла.

17. Муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органына Министрлыкка дөрес булмаган мәгълүмат биргән, шул исәптән түбәндәгеләр өчен җаваплылык йөкләнә:

хокук билгели торган гамәлдәге документларга таянып, җир кишәрлекләрен һәм аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын алу турында кабул ителгән карарларның нигезлелеге;

заявкадагы мәгълүматларның, шул исәптән бу Тәртипнең 10 пунктында күрсәтелгән чыгымнар өлешендә дөрес булмаганы.P102

18. Әгәр 2024 елның 31 декабренә карата муниципаль берәмлек тарафыннан килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенә ирешелмәгән булса, башка бюджетара трансфертлар муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансферт бирелгән елдан соң килә торган елның 1 мартына кадәр кире кайтарылырга тиеш.

19. Муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары бозылган, шул исәптән муниципаль берәмлек тарафыннан бу Тәртипнең 18 пункты нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына акча кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган мәҗбүр итү чаралары кулланыла.

20. 2025 елның 1 гыйнварына файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар акчалары башка бюджетара трансферт бирелгән елдан соңгы елның беренче 15 эш көне дәвамында Татарстан Республикасы бюджеты керемендә кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә түләтелергә тиеш.

Министрлыкның хисап финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турындагы карары нигезендә акча әлеге башка бюджетара трансфертларның калган өлешеннән артмаган күләмдә агымдагы финанс елында әлеге башка бюджетара трансфертлар бирү максатларына туры килә торган муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен алар элегрәк бирелгән муниципаль берәмлек бюджеты кеременә кире кайтарылырга мөмкин.

21. Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары бу Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

22. Муниципаль берәмлекнең җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмаган өчен законнар нигезендә җаваплы.

Башка бюджетара трансферттан максатчан файдаланмау Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча законнар белән билгеләнгән тәртиптә бәхәссез түләтүгә китерә.

23. Башка бюджетара трансфертларны максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә башкарыла.